**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 6 ноябрь

№ 847

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнүче һәм вазыйфадан азат ителүче, аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 ел, 27 июль, ФЗ-79 нчы Федераль законның 25 статьясындагы 4 өлешенең 1 нче пункты, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеге турында» 2017 ел, 6 октябрь, ПУ-889 нчы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнүче һәм вазыйфадан азат ителүче, аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\847.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 6 ноябрь, 847 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнүче һәм вазыйфадан азат ителүче, аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органы җитәкчесе
2. Татарстан Республикасы министрының беренче урынбасары.
3. Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары
4. Татарстан Республикасы министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы министрлыгының департамент директоры.
5. Татарстан Республикасы министры урынбасары.
6. Татарстан Республикасының дәүләт комитеты рәисе урынбасары.
7. Татарстан Республикасы министры урынбасары – Татарстан Республикасы министрлыгының идарә (департамент) башлыгы.
8. Башка республика башкарма хакимият органы җитәкчесенең беренче урынбасары.
9. Башка республика башкарма хакимият органы җитәкчесе урынбасары.

F:\KARAR\2017\847-1.docx